МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

31.10.2024 Казан ш. № под-1811/24

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 11 июлендәге № под-1209/22 боерыгы расланган мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм Татарстан Республикасы карамагындагы оешмаларның педагог хезмәткәрләрен, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы муниципаль һәм шәхси оешмаларның педагог хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

б о е р а м:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм Татарстан Республикасы карамагындагы оешмаларның педагогика хезмәткәрләрен, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы муниципаль һәм хосусый оешмаларның педагогика хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» (2022 елның 6 декабреннән № 2113/22, 2023 елның 8 ноябреннән № под-2002/23 Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) 2022 елның 11 июлендәге под-1209/22 номерлы боерыгы белән расланган мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һәм Татарстан Республикасы карамагындагы оешмаларның педагогика хезмәткәрләрен, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы муниципаль һәм хосусый оешмаларның педагогика хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентының 2 нче бүлегенең 2.2.1 пунктына, түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Аттестацияләү процедурасының аналитик һәм оештыру-техник тәэмин ителешен «Мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри осталыгын бәяләү үзәге» дәүләт автоном учреждениесе гамәлгә ашыра».

Министр И.Г. Һадиуллин